**Кукмара муниципаль районы**
**Манзарас авыл җирлеге Башкарма комитеты**

# КАРАР

**«26» гыйнвар, 2024 ел** **№10**

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «2024 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 23 гыйнварындагы 46 номерлы карары, «Татарстан Республикасында «Җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге Башкарма комитеты **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Манзарас авыл җирлегендә 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә 2024 елның 1 февраленнән җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 8370,20 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 31 гыйнварындагы 14 номерлы карарын 2024 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Манзарас авыл җирлеге җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Хабибуллина Р.Г.

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге Башкарма комитетының 2024 елның 30 гыйнварындагы 10 номерлы карарына 1 нче кушымта

**2024 елның 01 февраленнән Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегендә җирләү буенча исемлектәге гарантияләнгән хезмәтләрнең бәясе**

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сум)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3574,40 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (мәетен) зиратка илтү | 1150,3 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3645,5 |
| **Барлыгы** | **8370,20** |

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге Башкарма комитетының 2024 елның 30 гыйнварындагы 10 номерлы карарына 2 нче кушымта

**2024 елның 01 февраленнән Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегендә җирләү буенча исемлектәге гарантияләнгән хезмәтләрнең бәясе**

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сум)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Кәфенләү (киендерү) | 150,48 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3423,92 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (мәетен) зиратка илтү | 1150,3 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3645,5 |
| **Барлыгы** | **8370,20** |